| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ПИСЬМЯНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ПИСМӘН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** п.Подлесный **КАРАР**

2025 елның 15 сентябре №14

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкының муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукын тәэмин итү максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьялары белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы белән, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча 2025 елның 30 сентябренә 17 сәгать 30 минутта гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

3.Гавами тыңлаулар үткәрү 2025 елның 04 октябреннән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://parvo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: https://leninogorsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.В.Дементьев